| СОВЕТ НОРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» май 2023 ел № 80

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 декабрендәге 119 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башлыгының, Норма авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 нче номерлы «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларның, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, рәисләрнең, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру» турындагы карары һәм 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 нче номерлы «2018 елның 28 мартындагы 182 нче номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, рәисләрнең, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2022 елның 13 октябрендәге 144 нче номерлы «2018 елның 28 апрелендәге 127 нче номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисенә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне билгеләү турында»гы карарына (01.11.2018 №152, 09.10.2020 №11, 18.01.2022 №101, 25.02.2022 №109 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында»гы карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 декабрендәге 119 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башлыгы, Норма авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы «11163» санын «19039» санына алмаштырырга;

1.2. Карарның 1 нче кушымтасында «16750» санын «16437» санына алмаштырырга;

1.3. Карарның 3 нче кушымтасының 6 пунктчасында «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. Карарның 4 нче кушымтасының 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәткәрләрнең гомуми хезмәт хакы муниципаль хезмәт вазыйфасы нигезендә муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладыннан (алга таба - вазыйфаи оклад), сыйныф чины өчен айлык өстәмә түләү, тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү, муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен өстәмә түләү, айлык акчалата бүләкләү, норматив булмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация, аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр, еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү һәм матди ярдәмнән гыйбарәт.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет-ресурсында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов